ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                    КАРАР

07 02 2020 г. № 69

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 30 июлендәге 979 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының муниципаль хезмәт күрсәтүләр реестрын формалаштыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 30 июлендәге 979 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының муниципаль хезмәт күрсәтүләр реестрын фор-малаштыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктка түбәндәге сүзләр өстәргә: «Әлеге Нигезләмәнең тәэсире, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Түбән Кама муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында тиешле килешүләр төзегән очракта, җирлекләрнең муниципаль хезмәт күрсәтүләр реестрын формалаштырганда һәм алып барганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләргә дә кагыла.»;

1.2. 2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Реестрны формалаштыру Башкарма комитет идарәләре һәм бүлекләре, шулай ук Башкарма комитет карамагындагы учреждениеләр (алга таба – структур бүлекчәләр) тарафыннан билгеләнә торган хезмәтләр күрсәтү исемлеге нигезендә икътисадый фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

1.4. 5, 6, 9, 10, 11, 12 пунктларда «БАТБ» сүзен тиешле килештә «структур бүлекчәләр» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 5 пунктта «, бушлай яки Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән бәяләрдән (тарифлардан)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 6 пунктта «икътисадый анализ һәм транспорт бүлеге (алга таба текст буенча – ИА һәм ТБ)» сүзләрен «икътисадый фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлеге (алга таба текст буенча– ИФТ һәм ЭБ)» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 7 пунктта «Җитәкче күрсәтмәсе белән» сүзләрен «муниципаль хокукый акт белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.8. 10, 11 пунктларда «ИА һәм ТБ» кыскартылмасын «ИФТ һәм ЭБ» кыскартылмасына алмаштырырга;

1.9. 11 пунктта «Җитәкче күрсәтмәләре» сүзләрен «муниципаль хокукый акт» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 13 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма гаммәви мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Р.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов